
# Проектның темасы:
# “Мәсьәлә чишү”

**Эшнең барышы:**

Балта-пычкы алдык без
Нәни йортлар салдык без
Йортыбыз нәкъ уенчык
Кунагыбыз ...

Сыерчык



- Сыерчыкларны күрдегезме?
- Аларны ничек каршы алдыгыз?
- Мин сыерчыкларны күзəттем. Бик матур сайрыйлар.

- Лəкин ул кайда йоклар?
- Кайда йомырка салыр?
- Ничек бала чыгарыр?

Димәк, сыерчыклар өчен оя кирәк!



- Ә сыерчык оясын ничек ясарга дип укытучыдан сораган идек. Ул безгә менә шундый мәсьәләне чишәргә кушты. Бу мәьәләне без төркемнәрдә чишеп килдек.

Мәсьәлә: (3 кл.,математика М.И Моро,М.А. Бантова)

Безнең максат:

**Бу мәсьәләне чишәргә кирәк!**

5 бертөрле сыерчык оясы ясау өчен, 20 турыпочмаклык һәм 10 квадрат формасындагы такта кирәк. 1 сыерчык оясына ничә такта китә?

# -Уйлагыз, кыскача язылышны кем уңайлырак яза? (Таблица)

| Фигуралар | 1 сыерчык оясына киткән такта | Сыерчык оясы саны | Барлык такта |
|---|---|---|---|
| Турыпочмаклык | ? | 5 оя | 20 т. |
| Квадрат | ? | 5 оя | 10 т. |

?


- 5 саны нәрсәне белдерә?
- -20, 10 саны нәрсәне белдерә?
- Мәсьәләдә нәрсәне табарга кирәк?

# Чишү:

I ысул:

1) 20:5=4 (турыпочмаклык) – 1 сыерчык оясы өчен
2) 10:5=2 (квадрат) – 1 сыерчык оясы өчен
3) 4+2=6 (такта) кирәк

Җавап: 6 такта кирәк.



II ысул:
Шарты:

| Фигуралар | 1 сыерчык оясына киткән такта | Сыерчык оясы саны | Барлык такта |
|---|---|---|---|
| Турыпочмаклык Квадрат | ? | 5 оя | 20 һәм 10 |

Чишү:
1) 20+10=30 (такта)
2) 30:5=6 (такта) кирәк
Җавап: 6 такта кирәк.

III. Аңлатма төзү юлы белән

Шарты:

| Фигуралар | 1 сыерчык оясына киткән такта | Сыерчык оясы саны | Барлык такта |
| --- | --- | --- | --- |
| Турыпочмаклык<br>Квадрат | ? | 5 оя | 20 һәм 10 |

Чишу:


(20+10):5=6 20:5+10:5=6

Җавап: 6 такта кирәк.

# - Кайсы ысул уңайлырак?

# - Ни өчен?

Модельләштеререп тә куябыз:



Димәк:

Мәсьәлә чишү аша гипотеза дөрес дип табылды

# Рефлексия:

Ә без абый белән “Иң матур сыерчык оясы” бәйгесендә катнашып җинүче булдык.







- Әти, синең үзебезнең авылда оештырган яңа фермер хуҗалыгына да бу сыерчык ояларын илтеп куярбыз әле.

- Ә нигә бу кирәк сон, улым?

- Безнең фермер хуҗалыгын тагын да ямьләндереп, эшкә дәрт биреп көн дә сыерчыклар сайрап торыр. Кошларга ашарга күп булыр. Шулай булгач, бу сыерчыклар, салкыннар башлангач та , безне ташлап китмәсләр дип уйлыйм.

